РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.10.2023 Буа шәһәре № 265 Бк/к

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районында физик культура
һәм спортны үстерү» муниципаль программасына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 04 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законын, «Физик культура һәм спорт турында» 2008елның 08 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «2019-2026 елларда Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау хакында» 2019 елның 05 мартындагы 159 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын (05.06.2023 елгы үзгәрешләр белән) гамәлгә ашыру максатларында ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 мартындагы 60 Бк/к номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. Программаның кушымтасында «Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 9.2 п. өстәргә:

| Чара исеме | Башкарučылар | Гамәлгә ашыру | Индикаторлар | Индикаторлар билгеләнеше | Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме мең сум. |
|---|---|---|---|---|---|

| | | вакыты | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9.2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Батыр» спорт мәктәбе муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә футбол кыры белән каркас-чатыр белән капланган ябык футбол манежын оператив идарә итү хокукына беркетү белән бәйле рәвештә рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру. | БМР БК спорт һәм туризм бүлеге | 2023-2025 еллар | Саны(берәмлек.) | - | - | 11 | 18 | 25 | - | - | 1781,2 ТР 17,8 МР | 0 | 0 |

1.2. Программаның паспортындагы “Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары” юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары (мең сумнарда) | Программаны гамәлгә ашыру еллары | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | Гамәлгә ашыру вакытында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 90621,40 | 111890,18 | 97284,04 | 97551,94 | 97894,64 | 495242,20 |
| | Федераль бюджет | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0,00 |
| | Республика бюджеты | 7979,0 | 731,50 | 3025,61 | 796,05 | 797,15 | 13329,31 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Башка чыганаклар (бюджеттан тыш) | 8652,60 | 10053,3 | 9330 | 9330 | 9330 | 46695,9 |
| | Барлыгы | 107253,0 | 122674,98 | 109639,65 | 107677,99 | 108021,79 | 555267,41 |

1.3. Программа кушымтасында «Чыганак күрсәтелгән финанслау күләме, мең сум (2023)» баганасында в строке «Барлыгы пунктлар буенча » юлында «107858,45» санын «109639,65» санына алмаштырырга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Барлыгы пунктлар буенча: | 107253,0 | 122674,98 | 109639,65 | 107677,99 | 108021,79 |

«БАРЛЫГЫ» юлын киләсе редакиядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| БАРЛЫГЫ: | | | | | | | | | 555267,41мең. сум. |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л. Н. Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов